КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 7 сентябрь г.Казань № 795

2021 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга нормативларны, дәвалап бетерү (тернәкләндерү) вакыты дәвамлылыгы нормативларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2021 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга хезмәтләр күрсәтү күләмнәрен;

2021 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга норматив чыгымнарын;

2021 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерү (тернәкләндерү) вакыты дәвамлылыгы нормативларын.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга нормативларны, дәвалап бетерү (тернәкләндерү) вакыты дәвамлылыгы нормативларын раслау турында» 2019 ел, 28 август, 704 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 7 сентябрь, 795 нче
карары белән расланды

## 2021 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга хезмәтләр күрсәтү күләмнәре

(кеше)

| Т/с | Оешмалар | Дәваланып бетү (тернәкләнү) өчен җибәрелә торган барлык авырулар | Шул исәптән стационарда дәваланганнан соң | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | көчле миокард инфарктын, тотрыксыз стенокардияне, йөрәккә һәм магистраль кан тамырларына операцияләрне | баш мие кан әйләнеше нык бозылуны | умыртка сөяге үсешендә җитешсезлекләр һәм кимчелекләр, буыннар пластикасы булганда, эндопротезлар һәм реэндопротезлар ясаганда, кул-аякларны реплантацияләгәндә ортопедия, травматология операцияләрен | куркыныч төркемнәрендәге йөкле хатыннар авыруларын | шикәр диабетын |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1. | Шифаханә-курорт оешмалары | 4 928 | 2190 | 368 | 126 | 1 923 | 321 |
| 2. | Дәүләт медицина оешмалары, | 657 | - | 603 | 54 | - | - |
| | шул исәптән: | | | | | | |
| 2.1. | Яр Чаллы шәһәренең «Сугышлар ветераннары госпитале» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учре- | 359 | | 305 | 54 | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ждениесе | | | | | | |
| 2.2. | «Республика клиник невро-логия үзәге» дәүләт авто-ном сәламәтлек саклау учреждениесе | 298 | | 298 | | | |
| | Барлыгы | 5 585 | 2 190 | 971 | 180 | 1 923 | 321 |

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 7 сентябрь, 795 нче
карары белән расланды

2021 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга норматив чыгымнар

| Т/с | Дәвалап бетерү (тернәкләндерү) юнәлеше исеме | Норматив чыгымнар, койка-көн өчен сум |
|---|---|---|
| 1. | Көчле миокард инфарктын, йөрәккә һәм магистраль кан тамырларына, тотрыксыз стенокардиягә операцияләрне стационарда дәвалаганнан соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 1 371,36 |
| 2. | Баш мие кан әйләнеше нык бозылуны стационарда дәвалаганнан соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 1 364,75 |
| 3. | Умыртка сөяге үсешендәге җитешсезлекләр һәм кимчелекләр, буыннар пластикасы, эндопротезлар һәм реэндопротезлар ясаганда, кул-аякларны реплантацияләгәндә ортопедия, травматология операцияләреннән соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 1 347,15 |
| 4. | Куркыныч төркемнәрендәге йөкле хатыннар авыруларын стационарда дәвалаганнан соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 1 344,86 |
| 5. | Шикәр диабетын стационарда дәвалаганнан соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 1 340,48 |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 7 сентябрь, 795 нче
карары белән расланды

2021 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерү (тернәкләндерү) вакыты дәвамлылыгы нормативлары

| Т/с | Дәвалап бетерү (тернәкләндерү) юнәлеше исеме | Дәвалап бетерүнең (тернәкләндерүнең) дәвамлылыгы, календарь көннәр |
|---|---|---|
| 1. | Көчле миокард инфарктын, йөрәккә һәм магистраль кан тамырларына, тотрыксыз стенокардиягә операцияләрне стационарда дәвалаганнан соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 21 |
| 2. | Баш мие кан әйләнеше нык бозылуны стационарда дәвалаганнан соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 21 |
| 3. | Умыртка сөяге үсешендәге җитешсезлекләр һәм кимчелекләр, буыннар пластикасы, эндопротезлар һәм реэндопротезлар ясаганда, кул-аякларны реплантацияләгәндә ортопедия, травматология операцияләреннән соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 21 |
| 4. | Куркыныч төркемнәрендәге йөкле хатыннар авыруларын стационарда дәвалаганнан соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 21 |
| 5. | Шикәр диабетын стационарда дәвалаганнан соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 21 |